ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.08.2024 п.г.т.Алексеевское № 328

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларын нвентаризацияләүне үткәрү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы спорт министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү турында» 29.02.2024 ел, №86 боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү максатларында

**карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрүнең кушымтада бирелә торган Тәртибен (алга таба – Тәртип) (1 нче кушымта) расларга.

2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрү комиссиясе составын төзергә һәм расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеге башлыгы Р.Б. Сөләймановка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М. Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 15.08.2024
ел, № 328 карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрүнең әлеге тәртибе спорт инфраструктурасы объектларының, мәгариф оешмаларының тиешле инфраструктурасын да кертеп, фактта булуын ачыклау, аларны исәпкә алу, физкультура-спорт юнәлешендәге матди-техник базаның торышын билгеләү, эксплуатациядә хокук бозулар, спорт объектларыннан нәтиҗәсез файдалану һәм билгеләнеше буенча файдаланмау фактларын ачыклау максатында эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрү тәртибен билгели.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан, барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге, укыту-тренировка һәм физкультура-савыктыру дәресләре, спорт чаралары өчен билгеләнгән, гамәлдәге, шулай ук реконструкцияләнүче һәм капиталь ремонтланучы спорт инфраструктурасы объектлары инвентаризацияләнергә тиеш.

4. Инвентаризация уздырганда комиссия:

- инвентаризация объектлары хуҗаларының һәм алардан файдаланучыларның хокукларын раслый торган документларның булуын тикшерү;
- спорт объектына документлар булу-булмавын тикшерү (инвентаризация объектына исәп документлары булу: объектны файдалануга тапшыру актлары, техник паспортлар; объектны арендага бирү өчен документлар булу һәм башкалар);
- ябык һәм ачык инвентаризация объектларын карау, паспортлар, исәп карточкалары булу-булмавын тикшерү.

5. Инвентаризация объектларын исәпкә алу бланкларыннан мәгълүмат исемнәре һәм тиешле бүлекләре буенча исемлеккә кертелә. Инвентаризация объектларына исемлек электрон рәвештә алып барыла.

6. Эксплуатациядән чыгарылган, капиталь ремонт (реконструкция) үткәрүгә мохтаҗ инвентаризация объектлары, эксплуатациядәге хокук бозулар фактлары, спорт объектларыннан нәтиҗәле файдаланмау һәм билгеләнеше буенча файдаланмау ачыкланган очракта, комиссия аларны объектны эксплуатациягә тапшыру датасын һәм әлеге хәлгә китергән сәбәпләрне күрсәтеп, аерым исемлеккә кертә. Әлеге объектлар шулай ук гомуми инвентаризация исемлегендә күрсәтелергә тиеш. Теләсә нинди үзгәрешләр ачыкланганда (яңа ачыкланган объект, объектның милекчесе алмашыну, матди-техник торышы, объекттан файдалануның билгеләнеше үзгәрү һ.б.) объектка яңа паспорт яисә исәп карточкасы тутырыла, инвентаризация исемлегенә тиешле мәгълүмат кертелә һәм кичекмәстән Татарстан Республикасы спорт министрлыгына җиткерелә.

7. Инвентаризация үткәрү йомгаклары буенча комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы спорт министрлыгына инвентаризация объектларының исемлеге бирелә.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г. Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 15.08.2024
ел, № 328 карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларына инвентаризация үткәрү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Язынин Руслан Сергеевич | Комиссия рәисе,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Сөләйманов Рифкат Бариевич | Комиссия рәисе урынбасары,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеге башлыгы |
| Кондратьева Анастасия Николаевна | Комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБО инструктор-методисты |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Рыдаев Вячеслав Юрьевич | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге » МКО башлыгы |
| Кәбиров Рөстәм Рәшитович | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБО директоры |
| Егоров Владимир Евгеньевич | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кышкы спорт төрләре буенча спорт мәктәбе» ӨББ МБО директоры |
| Хәлитова Эльвира Рафаиловна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБО директорының урынбасары |
| Язынина Олеся Александровна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кышкы спорт төрләре буенча спорт мәктәбе» ӨББ МБО директорының урынбасары |

| | |
|---|---|
| Крохина Надежда Александровна | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе » МБО җитәкчесе |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г. Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районының спорт
инфраструктурасы объектларына
инвентаризация уздыру тәртибенә
кушымта_____________№________

# ИСӘП КАРТАСЫ

Спорт объекты турында белешмәләр

« __» ____________ ел

Инвентаризация объектының идентификация номеры:________________________________

1. Спорт корылмасының исеме: ________________________________________________

2. Спорт объектының урнашкан урыны:

2.1. Республика, край, өлкә: ______________________________________________

2.2. Район, шәһәр: ________________________________________________________

2.3. Урам, өй номеры: _____________________________________________________

2.4. Корпус, төзелмә: _____________________________________________________

3. Спорт корылмасының спорт төрләре буенча махсуслашуы: ____________ код ____________

4. Спорт корылмасының гомуми мәйданы: __________________ кв.м

5. Спорт объекты урнашкан җир кишәрлегенең гомуми мәйданы: ______ кв.м

6. Корылмалар буенча спорт корылмасы составы: (күләме, экспликация мәйданы ТИБ техник паспорты): _______________________

7. Җир кишәрлегенең кадастр (шартлы) номеры: __________________________________

8. Җир кишәрлегеннән файдалану хокукы: ____________________________________

9. Спорт объектын файдалануга тапшыру елы: _______ ел

10. Спорт объектына бәя характеристикалары:

10.1. Объектның баланс бәясе: _________ тыс.руб

10.2. Объектның калдык бәясе: _________ тыс.руб

11. ТИБ паспортын бирү датасы һәм номеры: «__» _______ ел N____________

12. Спорт объектының баланс тотучысы (тулы һәм кыскартылган исеме):____________________________________________________________

13. Спорт объектының баланс тотучы оешмасы турында белешмәләр:

13.1. Почта индексы: _____________________________________________________

13.2. Республика, край, өлкә: ______________________________________________

13.3. Район, шәһәр: ______________________________________________________

13.4. Урам, өй номеры: ___________________________________________________

13.5. Корпус, төзелмә: ___________________________________________________

13.6. Вазыйфа, җитәкченең Ф.И.А.: ______________________________________

13.7. Оешманы федераль мөлкәт Реестрына кертү турында таныклык

: «__» _________ ел N ________________

13.8. Милек формасы (ОКФС): ____________________________________________________

13.9. Код СООГУ/ОКОГУ (өстә торучы орган): ________________________________________

14. Спорт объектын балanска кабул итү-тапшыру актының датасы һәм номеры

: «__» ____________ ел N______________

15. Оешманың спорт объектына дәүләт теркәве турында таныклыкка ия булу хокукы:

________________________________________________________________________

16. Спорт объектына ия булу хокукын билгели торган документның исеме, датасы һәм номеры:

«__» ____________ ел N ____________________________

Комиссия рәисе: _____________________________________(Язынин Р.С.)

Рәис урынбасары: ____________________________________(Сөләйманов Р.Б.)

Комиссия секретаре: __________________________________(Кондратьева А.Н.)

Комиссия әгъзалары:__________________________________(Рыдаев В.Ю.)

_____________________________________(Кәбиров Р.Р.)

_____________________________________(Егоров В.Е.)

_____________________________________(Хәлитова Э.Р.)

_____________________________________(Язынина О.А.)

_____________________________________(Крохина Н.А.)